**IV Районкүләм сәләтле мөслимәләрнең “Хәят” кул эшләре бәйгесе.**

3 ноябрь көнне Бәзәкә мәдәният йортында “Хәят” кул эшләре бәйгесе узды. Бу бәйге- ярминкә авылыбызда инде өченче мәртәбә уздырыла. Халыклар бердәмлеге көненә дә бик матур чара булды бу. Бәйгедә төрле милләт вәкилләре катнашты. Менделеев шәһәреннән, районыбыз авылларыннан, Яр Чаллы шәһәреннән килгән кунакларыбыз арасында Уфадан килгән якташларыбыз да бар иде. Бәйге ике номинация: кул эшләре һәм милли ризык әзерләү буенча бәяләнде. Бәяләү комиссиясе Менделеев районы мөхтәсибәте тарафыннан билгеләнгән мөслимәләребез, ак яулыклы апаларыбыз иде. Конкурсантларыбыз үзләренең тәҗрибәләре белән уртаклаштылар, төрле татлы ризыклардан авыз иттеләр. Җиңүчеләребез Менделеев районы Имам-мөхтәсибе Ирек хәзрәт Нуриев имзалаган дипломнар белән һәм истәлекле сувенирлар белән бүләкләнделәр. Менә ул җиңүчеләребез:

Кул эшләре буенча:

| | |
|---|---|
| 1 урын | Гөлнур Нуретдинова (Бәзәкә авылы) |
| 2 урын | Фәния Бәшарова (Бәзәкә авылы) |
| 3 урын | Фидания Хуҗина (Бәзәкә авылы) |

Милли ризыклар әзерләү буенча:

| | |
|---|---|
| 1 урын | Тәнзилә Сибгәтуллина (Бәзәкә авылы) |
| 2 урын | Гөлназ Вәлиева (Тойгуҗа авылы) |
| 3 урын | Мәүлидә абыстай Исмәгыйлева (Бәзәкә авылы) |

(Җиңү яулаган авылдашларыбызны, якташларыбызны кайнар котлыйбыз! Катнашучыларыбызга зур рәхмәтләребезне белдерәбез!)

Бәйгедә катнашучылар бу чараны оештыручыларга Гөлфирә апа Фәизовага, Мехәмәтнур хәзрәт Назмутдиновка, мәдәният йорты хезмәткәрләренә рәхмәтләрен җиткерделәр һәм киләсе елларда да катнашырга теләк белдерделәр.


2019-11-3 08:48


2019-11-3 08:48


2019-11-3 10:27


2019-11-3 10:36


Юбилееӊ белән,
мәдәният йортым!






Без кабызган утлар


ДИПЛОМ
Wild Orchid


ДИПЛОМ
Luminarc